ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

18.04.2024 г. Заинск № 241

**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының 2006 елның 29 ноябрендәге 1518 номерлы «Торак бинаны торак булмаган бинага һәм торак булмаган бинаны торак бинага күчерү тәртибе һәм шартлары турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында, «Россия Федерациясе Торак кодексына һәм «Күчемсез милекне дәүләт теркәве турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 19 декабрендәге 608-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Зәй муниципаль районы Уставына таянып, Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты

**карар бирә:**

1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының 2006 елның 29 ноябрендәге 1518 номерлы «Торак бинаны торак булмаган бинага һәм торак булмаган бинаны торак бинага күчерү тәртибе һәм шартлары турында» карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1 пункт үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарны Зәй муниципаль районының рәсми сайтында http://zainsk.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүне Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасарына йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **Э.Э. Галеев**

Юрист
Э.Н. Кулагина
8(85558) 7-08-18